وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№11-12 (206-207). 11 октябрь 2013 /6 - зөлхиҗҗә-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ

## КОРБАН БӘЙРӘМЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

**Хөрмәтле дин кардәшләрем, ватандашларым!**
**Әссәләәму галәйкүм үә рахмәтүллаһи үә бәракәәтүһ!**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык дин кардәшләребезне Корбан гаете белән котлыйм! Күркәм бәйрәмебез - Корбан гаете барчаларыбызга мөбарәк һәм хәерле булсын!**

Корбан бәйрәме - Аллаһы Тәгалә ярдәме белән шәфкать-мәрхәмәт, изгелек кылу аша туганнарыбыз, дусларыбыз, күршеләребез һәм башка бик күп кардәшләребез белән якынаю көне ул.

Корбан чалу - кешеләр өчен Аллаһ тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган һәм безгә важиб булган изге гыйбадәтләрнең берсе. Мөмкинлеге булган мөселманнар Раббыбыз биргән нигъмәтләргә шөкер итү, мохтаҗларга ярдәм кулы сузу өчен корбан чала.

Корбан бәйрәме - исламның бишенче баганасы булган фарыз гамәл - хаҗ кылу тәмамлану көне дә. Миллионлаган хаҗилар һәм алар арасында безнең дә ватандашларыбыз, мөселманнарның изге йорты - Кәгъбәдә очраша. Кардәшләребез бөтен тормыш мәшәкатьләрен читкә куеп, туган җирләреннән меңләгән чакрым читтә Аллаһы Тәгаләнең әмерен үтәп хаҗ кыла, Аллаһы Тәгалә ризалыгына өмет баглап корбан чалу йоласын башкара.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәссәлам бер хәдисендә әйтә: "Аллаһ каршында көннәрнең иң бөеге - Корбан бәйрәменең беренче көне". Аллаһның иң бөек көнендә бәйрәм намазларын укырга, корбаннар чалырга, күңелләребездәге мәрхәмәт, куаныч-шатлыкны өләшергә язсын! Аллаһы



Тәгаләнең иксез-чиксез рәхмәтләренә барчабызга да ирешергә, гомерләребезне хәерле итеп үткәрергә насыйп итсен! Илкөннәребезгә тынычлык-иминлек, бәрәкәт бирсен!

**Мөфти Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН,**
**Үзәкләшкән дини оешма -**
**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе**

## "ИҢ ЯХШЫСЫН САЙЛАГЫЗ"

Быел мөселманнар өчен изге бәйрәмнәрнең берсе булган Корбан гаете 15 нче октябрьгә туры килә. Бу көнне мөселманнар ял итә.

"Татар-информ" мәгълүмат агентлыгында Корбан гаетенә һәм корбан чалу тәртибенә багышлап уздырылган видеоконференциядә Татарстан мөфтие урынбасары, Казанның Гаилә мәчете имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллин хәбәр иткәнчә, корбан бәйрәм намазыннан соң чалына. Рөстәм хәзрәт Хәйруллин әлеге вакытның иртәнге сәгать 8 тулып 10 минутта булуын хәбәр итте. Корбанны 15, 16 һәм 17 нче октябрьдә кояш баеганчы (ахшам намазы вакыты кергәнче) чалырга була. Быел корбан чалу өчен кирәк булган нисаб (запаста булган акча) күләме 12 мең сум итеп куелды.

Бурычлы кешегә корбан чалырга ярыймы-юкмы дигәндә, монда мәсьәлә бәхәслерәк. Бай кешеләрнең бурычлары булган очракта да, аларның корбан чалырлык кына акчасы бар. Шуңа күрә аларга корбан чалдыру лазем. Ә инде гади кешенең бурычлары булып, ипотекасын түләмичә, корбан чалдыра икән, гаиләсенә зыян салырга мөмкин. Шуңа күрә һәркем үзе хәл итәргә тиеш.

Корбанлыкка сарыклар, кәҗәләр, сыер һәм үгез суярга ярый. Кәҗәгә бер яшь тулган булырга тиеш. Сарыклар зур гәүдәле булып күренә икән, ярты еллык булса да чалырга рөхсәт ителә. Сыерлар һәм үгезләргә ике яшь тулган булырга тиеш. Дөяләр чалу да рөхсәт ителә. Рөстәм хәзрәт Хәйруллин үзебездә таралган малларны чалу хәерлерәктер, дип белдерде. Мөгезле эре терлекне җиде кеше җыелып, корбанга чала ала. Эре терлекне чалганда барлык кешеләрнең дә корбанлыкка дип ниятләве кирәк. Әгәр берәрсе булса да иткә дип кушыла икән, бу корбанлыктан китми.



Корбанлыкның тышкы кыяфәтенә карата да шартлар куела. Пәйгамбәребез (с. г. в.): "Сез сарыкны сайлаганда иң яхшысын сайлагыз", - ди. Аның мөгезләре сынмаган, койрыгы өзелмәгән булырга, күзе күрергә тиеш. "Корбан" сүзе Аллаһка якынаю дигәнне аңлата, без Аллаһ ризалыгы өчен иң яхшы булган әйберне Аңарга корбан итәбез. Шуңа күрә әгәр дә сарыгы, сыеры кимчелекле икән, ул корбанга туры килми, аны чалудан файда булмый", - диде хәзрәт.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

***Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин нәзарәтнең Голәмәләр советы тәкъдиме буенча бәйрәм вәгазен һәм намазын уку вакытын раслады. Казанның барлык мәчетләрендә бәйрәм вәгазе - иртәнге сәгать 7 тулып 20 минутта (7.20), намаз сәгать 8 туларга 10 минутта (7.50) башлана.***

***Колшәриф мәчетендә гает намазы башка мәчетләрдә укылган вакытта укылачак. Узган елларда мөселманнар үз җирлекләрендәге мәчетләргә Колшәриф вакыты белән килгән һәм бәйрәм намазын укый алмаган. Шуңа күрә быел, Татарстан мөфтие карары белән, барлык мәчетләрдә дә вакытны бер төрле билгеләгәннәр. Шулай да Колшәриф мәчетеннән бәйрәм намазы телевидениедән күрсәтеләчәк дип көтелә.***

***Бәйрәм намазыннан соң иртәнге сәгать 8 тулып 10 минутта (8.10) корбан чалына. Быел корбанны 15, 16 һәм 17 нче октябрьдә кояш баеганчы (ахшам намазы вакыты кергәнче) чалырга була.***

## ЯҢАЛЫКЛАР

### Рәсми кунаклар Болгарны карады

**9нчы октябрь көнне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев Россия хөкүмәте рәисенең беренче урынбасары Игорь Шувалов һәм Евразия икътисад комиссиясе әгъзалары белән берлектә Болгарны карады.**

Рәсми кунакларны Болгарның дини кыйммәтләре белән Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин таныштырды.

### Нәзарәткә мөхтәсибләр җыелды

**Кичә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә Корбан бәйрәме уңаеннан мөхтәсибләр җыелышы уздырылды. Җыелыш Коръән аятьләре укудан, дога кылудан башланды. Чара мөхтәсибләргә, олуг бәйрәмгә кадәр очрашып, Корбанга һәм мәчетләргә, көнкүреш мәсьәләләренә кагылышлы мәгълүматларны җиткерү максатыннан оештырылды.**

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин мөхтәсибләрне якынлашып килүче Корбан бәйрәме белән котлады һәм кайбер чаралар белән таныштырып үтте.

"Шура" әлманахының икенче саны дөнья күрде. Анда 13 вәгазь, хәнәфи мәзһәбенә кагылышлы язмалар, сорау-җаваплар, динебез тарихына кагылышлы мәкаләләр урын алган. Журнал Татарстандагы һәр имамга да биреләчәк", – диде Камил хәзрәт. Әлеге басма, авыл имамнарына таратыр өчен, һәр район мөхтәсибенә тапшырылды.

Мөфти шулай ук тагын бер китап чыгуы хакында хәбәр бирде: "Нәзарәт тарафыннан уздырыла торган Мәрҗани елы уңаеннан, Шиһабетдин Мәрҗанинең җәйге вакытта ястү намазын укуга багышланган китабын иске басмадан җыеп бастырдык. Киләсе атнага ул тулысынча нәшер ителеп бетәчәк".

Камил хәзрәт Сәмигуллин җыелышта "Хәләл" стандарты комитеты җитәкчесе Марат Низамовны дини эшчәнлек алып баруда, хәләл брендын киң җәмәгатьчелеккә танытуда зур тырышлык куйганы өчен нәзарәтнең "Халкыбызга хезмәте өчен" медале белән бүләкләде.

### Саматов укулары үткәрелә

**12 нче октябрь көнне Россия ислам институтында (Казан шәһәре, Газовая ур., 19нчы йорт) Татарстан мөфтияте, Россия ислам яңарышына зур өлеш керткән татар дин әһелләре эшчәнлеген өйрәнү максатыннан, Саматов укулары фәнни-гамәли конференциясен уздыра. Дүртенче тапкыр үткәрелә торган Саматов укулары "Идел-Урал төбәге мөселманнары рухый мирасын аңлау" дигән темага үткәрелә.**

Татарстанның беренче казые Габделхак хәзрәт Саматов – XX гасыр ахыры – XXI гасыр башының күренекле дин әһеле. Хәзрәт татарларның революциягә кадәрге дини-рухый мирасын дәвам итеп, бүгенге заманга кайтаручы һәм бик күпләрнең рухый остазы булган шәхес.

Конференция кысаларында Г.Саматов исемендәге "Рухый мирас" премиясе дә тапшырылачак.

Мәгълүматлар Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды.

# КОРБАН ЧАЛУ – ГЫЙБАДӘТ УЛ

**Корбан бәйрәме – ислам дөньясында иң олы, мөбарәк бәйрәмнәрнең берсе. Якынлашып килүче Корбан бәйрәме һәрберебезнең күңеленә иман нуры өстәсә иде. Бу көн безнең өчен кылган гөнаһларыбызның ярлыкануы, Аллаһ кушмаган гамәлләрдән тыелу, үзеңә һәм әйләнә-тирәдәгеләреңә, фәкыйрьләргә, ятимнәргә шатлык бүләк итү көне буларак кадерле.**

Кабат Ибраһим гәләйһиссәламнең: "Әгәр дә миңа угыл бала бирсәң, мин шул баламны корбан итеп чалырга әзер", – дигән сүзләрен искә төшерәсе килә. Ләкин Аллаһы Тәгалә бәндәләрнең каннарын түгүче түгел, ул бары шул рәвешле пәйгамбәребезнең иманы ныклыгын күрсәткән. "Йә Ибраһим, Раббыңа әйткән нәзереңдә тугрылыклы булуыңны исбатладың. Аллаһ синнән разый булды. Инде корбан итеп улыңны түгел, куй чал", – дип аңа бер сарык җибәргән. Шул көннән башлап дөньядагы барча мөселман халкы Корбан чала. Әлеге бәйрәм көннәрендә Аллаһы Тәгаләнең бөеклегенә, исламның хак дин булуына тагын бер кат инанып мохтаҗларга, ятимнәргә, төрле бәла-казаларга юлыккан мөселман кардәшләребезгә хәлдән килгәнчә ярдәм кулы сузыйк, туганнарыбыз, күршекүләннәребезнең хәлләрен белешик!

Корбан чалуга карата халыкта еш кына сораулар туып тора. Шул сорауларның кайберләренә Татарстанның Кама буе төбәге казые **Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИЕВ** җавап бирә.

**– Корбан чалу ислам динендә нинди урын тота? Ул һәркем өчен дә мәҗбүриме? Ничек башкарыла?**

–Төп ихтыяҗларын исәпкә алмаганда (мәсәлән, торак, кием, машина, өй җиһазлары), малы 12000 сумга җиткән, мосафир булмаган мөселман кешегә корбан чалу ваҗибтыр, ягъни мәҗбүридер. Корбан чалу мәҗбүри булган очракта корбан бер кеше исеменнән генә чалына һәм ул үз гомеренә бер тапкыр түгел, бәлки мәҗбүрилеге булган һәр елны чалынырга тиеш. Оешмада эшләүче кешеләр исеменнән, мәхәллә халкы исеменнән, гаилә исеменнән нәфел корбаны чалынырга мөмкин. Бу очракта оешмада эшләүче кешеләр, мәхәллә һәм гаилә әгъзалары өстеннән корбан чалу ваҗиблыгы төшми. Бу әйтеп кителгән кешеләр арасыннан корбан чалу мәҗбүрилеге булган һәркем үзе корбан чалырга тиеш. Аллаһның илчесе галәйһиссәлам: "Кемнең корбан чалырга мөмкинлеге булып та, моны эшләмәсә, мәчетебезгә якынлашмасын", – дип кисәткән. Корбан чалуны исә һәр кеше үзе үтәсә әйбәтрәк. Иң башта терлекне кыйблага каратып яткырырга кирәк. Ул аягында чакта корбан догасы укыла. Аннары: "Әй Раббым! Ошбу хайванны Синең әмерең буенча чаламын. Әй Раббым! Кабул кыл. Бисмилләһи, Аллаһу әкбәр!" – дип ниятләп, корбанлык бугазы киселә.

Әгәр төрле сәбәпләр аркасында кеше бу эшне үзе башкара алмый икән, башка кешегә тапшырып, карап тора ала. Тик өч шартны үтәргә кирәк. Беренчедән, бу кеше мөселман булырга тиеш. Икенчедән, корбан чалуны үтәүченең: "Әй Аллаһ, бу корбанны фәлән улы фәләннән, яисә фәлән кызы фәләннән кабул ит", – дип әйтүе кирәк. Өченчедән, ул кешегә чалына торган корбанның ите белән түләргә ярамый.

**– Кайбер гаиләләр корбанны гает намазына кадәр чалып куя. Болай эшләү дөресме?**

– Гает укылганчыга кадәр чалынган корбан дөрес булмый. Моның турында Пәйгамбәребез (с. г. в.) дә әйтеп калдырган: "Кем гаеткә кадәр корбан чала, бу аның гаиләсе өчен ит кенә булыр, ә корбан чалу йөкләмәсе аның өстеннән төшмәс". Шулай ук бу эшне караңгы төшкәч тә башкару киңәш ителми, чөнки шартлары үтәлеп бетмәскә мөмкин, мәкруһ.

**– Корбанлык өчен нинди хайван сайлау кирәк?**

– Корбанлык өчен пар тояклы – кәҗә, сарык, дөя, сыер кебек хайваннарны алу кирәк. Каз, үрдәк, күркә кебек кошларны, атларны чалырга ярамый. Шулай бер күзе сукыр, йөри алмаслык аксак, бер колагының, я бер мөгезенең, я койрыгының өчтән бер өлеше киселгән; колаксыз, койрыксыз һәм бик ябык хайваннарны корбанга чалу дөрес түгел. Яшенә килсәк: дөягә – биш яшь; үгез яки сыерга – ике яшь; кәҗә, сарык малына бер яшь булу шарт. Куй сарыгы (бу бары куй сарыгына карый) бик зур һәм симез булып, бер яшьлекләреннән аерылмаса, алты айлыкларын да чалу ярый. Ә эре маллар бу кагыйдәгә карамый. Тик шунысын истән чыгармаска кирәк. Сарык һәм кәҗә бер кеше өчен генә корбан кылына, ә сыер яки дөя – җидешәр кеше өчен (күп дигәндә). Шулай ук бер үзеңә яисә җидедән ким кеше саны булган бер төркемгә дә бер сыер, бер дөя корбан чалу да дөрес. Әгәр араларыннан берсе ит өчен катышса, һичберсенең өлеше корбаннан хисапланмас.

**– Нәзер итеп чалына торган корбаннар бар. Монда берәр нинди чикләүләр, халык белеп бетермәгән гамәлләр юкмы?**

– Нәзер корбанын чалу гает көне белән бәйле түгел. Бу эшне нәзере үтәлгәннән соң башкару лазем. Корбан фәлән нәзер үтәлгәне өчен дип чалына Мондый итне үзеңә ашарга ярамый, гаиләнең башка әһелләре ашый ала, яисә аны тулысынча таратып бетерергә кирәк, мохтаҗларга таратсаң хәерлерәк була.

– Корбанлыкны ничек дөрес итеп бүлергә?

– Җиде кеше бер хайванны корбан кылганда, ит үлчәү белән килограммлап бүленергә тиеш, кисәкләп чама белән бүлү дөрес түгел. Аллаһның илчесе галәйһиссәлам шулай аңлаткан: "Ашагыз, ашатыгыз һәм саклагыз". Бай кеше корбанны? итен өч кисәккә бүлеп, бер өлешен фәкыйрьләргә өләшү, икенче өлеше белән кунакларны хөрмәт кылу һәм өченче өлеше белән өй җәмәгатьләрен хөрмәт кылу мөстәхәб (саваплы) санала. Бай булмаган кешегә өй җәмәгатьләрен генә хөрмәт кылу да дөрес. Ә тиресен исә сатып, акчасын сәдака итеп бирү мөстәхәб була. Аны сатып, акчасын үз кирәгеңә тоту дөрес түгел. Әмма



сатмыйча күн итеп яисә тун тегеп куллану дөрестер.

**– Сыерны корбанга чалганда җиде кеше арасына мәрхүмнәрне кертергә ярыймы?**

–Мәрхүмнең өлешен сәламәт кешеләрнең корбанына катыштыру мәкруһ.

**– Корбан чалмыйча, чалдырмыйча акчасын гына мәчеткә яки мескеннәргә бирергә ярыймы?**

– Корбан чалу – кешеләр өчен Аллаһ тарафыннан билгеләнгән, пәйгамбәрләр кылган вә безгә кушып калдырылган изге гыйбадәтләрнең берсе. Корбан чалуны акча биреп кылына торган гыйбадәткә әйләндерү дөрес түгел.

**– Кояш баткач, караңгы вакытта корбан чалынамы?**

– Корбан чалу – бәйрәм көнен дә санап, өч көн дәвам итә. Өченче көннең кояшы баеганчы корбан суюлар тамамланырга тиеш. Корбанны кич һәм төнлә бугазлау мәкруһ.

**– Әгәр кеше кушылган көннәрдә корбан чалып өлгермәсә, нишләргә?**

– Гозерсез сәбәпләр белән гает көннәрендә корбан чала алмаган кешегә корбанлыгын яки аның бәясен фәкыйрьләргә сәдака итеп бирү тиешле.

***Әңгәмәдәш –***
***Нияз САБИРҖАНОВ***

**Корьәни-Кәримдә корбан чалу турында болай диелгән:** "Аллаһы Тәгалә мәсҗид Хәрәмдәге Кәгъбәне мөселманнарга кыйбла кылды, аның белән ислам дине һәм мөселманнар каим булып яшәр, сугышу хәрәм булган айларны, корбан чалуны һәм мәсҗид Хәрәмдәге яки хаждагы ачык галәмәтләрне мөселманнар файдасына кылды. Корьәндәге бөтен хәбәрләр сезгә сөйләнә – дөреслектә Аллаһы Тәгаләнең җирдә вә күкләрдә булган нәрсәләрне белгәнлеген белүегез өчен, әлбәттә, Аллаһ һәрнәрсәне белүче" (5:97).

"Корбан дөяләрен Аллаһ диненең галәмәтләреннән кылдык, аларда сезнең өчен дөньяда файда, ахирәткә савап бар, аякларында торган хәлләрендә бугазлаган вакытыгызда Аллаһ исемен зикер итегез, әгәр бугазлагач яннары илә җиргә төшсәләр, аларны ашагыз вә канәгатьле фәкыйрьгә вә оялып сораучы фәкыйрьгә ашатыгыз! Ул дөяләрне аяк өстендә бугазлауны бәян иткәнебез кеби аларны сезгә файдаландырдык, шаять, шөкер итәрсез" (22:36).

"Раббың ризалыгы өчен намаз укыгыл һәм ятимнәрне вә фәкыйрьләрне ашатыр өчен корбан чал!" (108:2).

**Корбан чалу турында пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) әйткән:** "Дөреслектә, бу көнебезне намаз уку белән башларбыз, аннан кайтып корбаннарыбызны чалырбыз. Шулай эшләгән бәндә сөннәтебезне үтәгән булыр".

# "ИҢ ЯХШЫСЫН САЙЛАГЫЗ"

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Казанда корбан чалу урыннарына килгәндә, эшләр болайрак тора. "Корбан чалуны оештыру мәсьәләсе безне - дин әһелләрен борчый. Еш кына корбан чалганда - кешеләр кан күргәндә этик, санитар нормалар бозыла. Корбан чалуны карап тору кайберәүләргә психологик яктан авыр тәэсир итә. Шуңа күрә без дәүләт структуралары белән берлектә бу эшне җайга салырга тырышабыз. Корбан чалу аерым җиһазландырылган урыннарда башкарылырга тиеш дип уйлыйбыз. Мондый урыннар Мәрҗани, Котдус, Ярдәм, Гаилә һ. б. мәчетләр территориясендә бар. Әлеге ябык урыннарга балалар гына түгел, корбан чалдыра торган олылар да керә алмаячак", - дип аңлатты Рөстәм Хәйруллин.

Бертуган Петряевлар урамындагы махсус комплекска килгәндә, әлеге җир юридик яктан Татарстан мөфтиятенә карамый. Шулай да анда корбан чалынмый дигән сүз түгел.

Корбан чалдырырга теләүчеләр корбанлык терлек сорап мәчетләргә мөрәҗәгать итә ала. Казан мөхтәсибәтендә белдерүләренә караганда, быел Мәрҗани, Кабан арты, Ризван, Әҗем, Нурислам, Ярдәм, Сөләйман, Хөзәйфә, Ислам һәм башка зур мәчетләрдә корбанлыклар әзерлиләр. Ярдәм мәчете корбан итеп мөгезле эре терлек чалырга теләүчеләрдән генә гаризалар кабул итә. Гаризалар 15 нче октябрьнең иртәсенә кадәр кабул ителә.

Гомумән алганда, Казан мәчетләрендә бүгенге көнгә меңнән артык корбан чалыначагы турында мәгълүмат бар. Корбанлыкның бәясе якынча 5-6 мең сум. Корбанлыклар Татарстан районнарыннан китертелә, Әстерхан, Волгоград, Оренбург өлкәләреннән кайтартыла. Бу эш белән республика фермерлары шөгыльләнә. Корбанлыкны сайлап алганда сатулашу рөхсәт ителми. Бу - пәйгамбәребездән калган тәртип.

Корбан итенең - бер өлешен гаиләңә калдырырга, икенче өлеше белән корбан ашы үткәрергә, өченче өлешен фәкыйрьләргә һәм ятимнәргә кертергә кирәк. Шулай ук бөтен итне мохтаҗларга таратып бетерсәң дә була. Мөселман булмаган күршеләрне һәм туганнарны корбан ите белән сыйлау саваплы гамәл санала. Корбанның маен этләргә, мәчеләргә бирергә рөхсәт ителә. Ә сөякләрен шәһәрдә - гомуми урыннарда, авылларда аулак урыннарда күмәргә кирәк.

Корбан чалуны оештырганда, санитар нормалар сакланырга тиеш, дип саный хәзрәт. Корбан чалына торган мәчетләрнең имамнары корбанлыкларның санитар нормаларга туры килү-килмәве турында белешмәләре бармы-юкмы икәнлеген контрольдә тотарга тиеш. Әгәр белешмәләре булмаса, тикшерүче органнар мондый сарыкларны чалырга рөхсәт бирми.

Районнарда корбан чалу, нигездә, Үзәк мәчетләрдә алып барыла. Анда Россия Куллanuчылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча идарә вәкилләре булачак. Казанда әлеге оешма вәкилләре бөтен мәчетләрне дә карап бетерә алмаячак. Димәк, бөтен җаваплылык имамнар һәм корбанлыклар белән тәэмин итүчеләр намусында кала.

***Римма ГАТИНА,***
***"Татар-информ"***

# ГАСЫР МУЛЛАСЫ

**Динебезгә, татар милләтенә зур афәтләр, һәлакәтләр китергән алласызлык дәвере, ниһаять, тәгәлләнеп килә.**



Авыр вакытларда да халкыбызда динне сакларга омтылучы ихлас диндарлар табылды. Төрле кысуларга, янауларга да карамастан, алар халыкны ислам дине белән таныштырды, иман нурын таратты. Шул фидакарьләр арасында Габделхак хәзрәт Саматов та бар. Исеме дә, фамилиясе дә җисеменә туры килгән ләбаса. "Габдел" сүзе гарәпчәдән Аллаһ колы, Аллаһ бәндәсе, "Хак" - чын, хак, дөреслек мәгънәләрен аңлата. "Самат" - мәңге яшәүче зат. Башлык дигән мәгънәгә туры килә. Кыйбланы алыштырмыйча, шушы исемнәргә лаек булып яшәү Саматовлар гаиләсендә исламның әһәмиятле урында булуына ачык дәлил.

Габделхак хәзрәт Саматовка дин әһеле буларак Татарстанда һәм төрле төбәкләрдә диннең күтәрелеп китүе өчен шактый гамәлләр кылырга язган. Ул авыр елларда да күпме кешене иманлы, кыйблалы итеп, халкыбызның рухый мирасын сакларга тырышты. Югарыдан кисәтүләргә карамастан, күп мәшәкатьләр белән Үзбәкстанның Бохара шәһәрендәге "Мир-Араб" мәдрәсәсендә дини гыйлем ала алды. 1980 нче елда аны Казанның Мәрҗани мәчетенә имам итеп куйдылар.

Ул галим, имам-хатыйб, казый, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсен оештыручы һәм аның беренче директоры, мөгаллиме һәм тәрбиячесе дә әле. Ислам диненә, милли тарихка кагылышлы, шәригать хөкемнәре буенча күп төрле сорауларга җитди җаваплар тупланган китапларның авторы да ул иде. Дин, милләт, халык өчен көрәшкә һәрчак әзер иде. Әмма хәзрәтебез Татарстанда баш мөхтәсибәтнең идарә башлыгы вазыйфаларын үтәгән чакта халыкларны сабырлыкка, тынычлыкка чакырды, беркайчан да сәяси сугыш-талашларда катнашмады, һәрвакыт төрле каршылык һөҗүмнәренә сабырлык белән җавап бирде. Татарстанда аерым яшәп килгән диния нәзарәтләре берләшкәч, халык имамнары Габделхак хәзрәтне берләшкән Диния нәзарәтенә Баш казый итеп сайлап куйды.

Татарстанның Баш казые вазыйфасын үтәгәндә, Габделхак хәзрәт "Баш казый хөкемнәре" дигән дини аңлатмалар әзерләде. Ул текстлар югары сыйфатлы илаһият казанышлары булып тора. Остазыбыз гаҗәеп китаплар язып калдырды. "Сорау-җавап" китабын карагыз сез, гади халык, дин белән кызыксыну һәркем аңларлык итеп бирелгән андагы җаваплар. Ә "Шәригать" дигән өч томлык китабы халкыбызга нинди зур белем хәзинәсе булып ирешә. "Милләтебездә ислам дине" китабы милләтебезнең ислам динен кабул иткәннән башлап бүгенге көнгә кадәр булган дин әһелләрен барлап язган искиткеч бай мәгълүматлы тарихый яктан бәһасез хезмәт. Хәзрәтнең ислам динебез кушканча яшәргә теләүчеләргә кушыла торган исемнәр хакындагы китабы һәм башка китаплары да киләчәк буыннарга өстәл китабы булырлык хәзинә. "Дөреслектә галимнәр пәйгамбәрләрнең варислары һәм галимнәр мирас итеп дирһәм дә, динар да калдырмыйлар, ә гыйлемне мирас итеп калдыралар", - диелә бит хәдистә дә.

Габделхак хәзрәтнең иң соклангыч сыйфатлары - аның түбәнчелекле, ләкин батыр булуы. Аллаһ диненә мәхәббәте шулкадәр көчле, Коръәни-Кәримне бик олылый иде. Мәҗлесләрдә сәгатьләр буе вәгазь сөйли, халык аны тыңлап туймый иде. Ул гомере буе халыкта Аллаһка, Аллаһның хак илчесенә, динебезгә мәхәббәт тәрбияләде.

Мәшһүр шәхес Габделхак хәзрәт Саматов безгә үзеннән соң зур мирас калдырды. Сүзем Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә турында.

Габделхак хәзрәт Саматов 1990 нчы елда Чистай шәһәрендә мәдрәсә ачуга ирешә. Чистайда бер ел укыткач, мәдрәсәнең башкалабызда булуын теләп, үзенең шәкертләре белән Казанга күчә. Мәдрәсә "Кабан арты" мәчетендә урнаша һәм шулай итеп, 1991-1992 нче уку елы Казанда башланып китә... Ә инде 1998 нче елда мәдрәсә Яңа татар бистәсендәге Ал мәчет бинасына күчә һәм 1998-1999 нчы уку елын ошбу мәчеттә башлап җибәрә һәм бүген дә шул урында эшләвен дәвам итә. Моны хөрмәтле Габделхак хәзрәтебезнең батырлыгы дими ни дисең?!

Күренекле дин галиме, энциклопедист, мәгърифәтче Шиһабеддин Мәрҗани үзенең "Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар" дигән китабында ислам тәгълиматының әһәмияте турында болай ди:

"Гыйлем һәм мәгърифәт белән шөгыльләнү, акыл белемен һәм камиллекне өйрәнү һәр сәламәт акыл, аек аң каршында, һичшиксез, кирәкле сыйфат, ә бу өлкәдә тырышлык һәм бер-беренә киң ярдәм күрсәтү, берсүзсез, күркәм эш. Зирәк шәхесләр һәм акыл ияләре карашынча, хаклыгы ачык гыйлем - ул иң кадерле сыйфатларның берсе, камиллекнең иң мактаулысы, ә гыйлем өйрәнү - рәхәтлекнең һәм бәхетнең иң югары дәрәҗәсе икәнлеге ачык".

...Бу сүзләр, әйтерсең лә, остазыбыз, мәгърифәтче, галим, сәясәтче Габделхак хәзрәт Саматовны күздә тотып язылган.

***Ибраһим хәзрәт ШАМИЛОВ,***
***Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә мөгаллиме, кичке уку бүлеге җитәкчесе***



# ХӨРМӘТЛЕ ГАБДЕЛХАК ХӘЗРӘТ ЯДКӘРЕ

**Безнең буынга да ил тарихындагы, ил язмышындагы төрле борылышларны күрергә туры килде.**

Узган гасырның 20 нче елларыннан башланып җиде дистә ел буена, ә инде сугышка кадәрге чорда аерым бер катылык, дәһшәт һәм миһербансызлык белән алып барылган диннән ваз кичтерү, динсезлекне сеңдерү идеологиясе үз эшен эшләгән булып чыкты: күңел күзе сукырайган халык маңгай күзе күргәнгә генә ышанып, дәһрилек чоңгылына чума барды, инде шул чоңгылдан чыгасы да килмичә, ялган идеаллар белән исереп, шул исереклектән (һәм туры мәгънәсендәге исереклектән) рәхәт табып яшәүгә күнде. Дини кыйммәтләрнең аяк астына салып тапталуына әрнеп, сугышта чагында да Коръән аятьләреннән аерылмаган, шул мәхшәрдән исән калуын нәкъ менә ялваруларының Аллаһка барып ирешүеннән күрүче әтием: "Ай-һай, бу халыкны иманга китерергә пәйгамбәр кирәк..." – дип куя иде.

Аллаһның рәхмәте белән, үз өсләренә авыр миссия – милләттәшләренә хак юл күрсәтү вазыйфасын алган кешеләр табылды. Алар затлы нәселләрдән булып, гаиләдә алган дини-рухый тәрбия җебен гомерләре дәвамында өзми саклап килгән асыл затлар иде. Вәгазьләрен тыңлаган, гамәлләрен күргән шундый шәхесләр – Габделхәбир хәзрәт Яруллин, Вафа хәзрәт Гыйлаҗиев, Харис хәзрәт Салихҗан һәм, әлбәттә инде, Габделхак хәзрәт Саматовлар белән аралашып яшәргә насыйп булды.

Габделхак хәзрәт гаҗәеп дәрәҗәдә эрудицияле, киң карашлы, тирән белемле, югарыдан карап фикер йөртүче, шул ук вакытта үтә гади кеше иде. Ул кайда гына чыгыш ясамасын – мәчет мөнбәреннәнме, телевидение, радиоданмы, авыл яки шәһәр җыен-мәйданнарындамы – җәмәгатьне үтемле сүзе белән бик тиз яулап ала белде. Хатын-кызга хөрмәт белән каравы турында аерым әйтәсем килә. Бу инде аның югары культурага ия булуын күрсәтә иде. Кайбер тәкәббер динчеләр кебек хатын-кызга шайтанга яки гөнаһ шомлыгына караган кебек карау аның өчен ят, чит, мөмкин булмастай гамәл иде. Габделхак хәзрәт чын халык педагогы, психолог иде. Шуңа да күңелендә иман бөртекләре йөрткәннәр аңа ышанды, иярде.

Габдулла Тукай музеендагы бер очрашуны искә алып үтим әле. Гомумән, бу музейда танылган дин әһелләрен чакырып очрашулар уздыру музейның ул чактагы директоры Фәрит Яхинның күркәм эше булды. Шундый мәҗлесләрнең берсен онытасым юк. Анда Габделхак, Харис, Габделхәбир хәзрәтләр катнашты. Безне бит бала чактан: "Тукай хәзрәтләрне тәнкыйтьләгән, дин дошманы булган, шуңа күрә дин әһелләре шагыйрьләрне сөймәгән", – дип өйрәттеләр. Ә монда хәзрәтләр, берсен-берсе алыштырып, Тукай шигырьләрен яттан сөйләп китте! Шунда халык шагыйрьнең әлегәчә укыганым булмаган дини-тәрбияви шигырьләрен ишеттем: "Тәәссер", "Ана илә бала", "Әни", "Ана догасы", "Таян Аллага" һ. б. "Туган авыл" шигырен Габделхак хәзрәт тулысынча, китапларга кертелми калдырылган өлешен дә өстәп укыды. Хәзрәтләр шигырьләргә аңлатма да бирде. Җыелган халык Тукайның кайсы динчеләрне тәнкыйтьләгәнен, кайсыларын зурлаганын аңлат китте. Мин дә шул көнге тәэсирләремне күңелемдә йөртеп, Г.Тукайның хәзрәтләр тарафыннан укылган берничә шигырен көйгә салдым.

Габделхак хәзрәт классик һәм милли мәдәнияттән яхшы хәбәрдар кеше иде, әдәбиятны, сәнгатьне яратты, әдәбият-сәнгать әһелләре белән аралашып яшәде. Безнең гаилә белән дә дустанә мөнәсәбәттә торды. Ирем Хәйдәр дә, мин дә аны бик хөрмәт иттек, киңәшләрен тоттык. Кайбер дини-рухый борынгы әсәрләрне өйрәнеп халык алдына – сәхнәләргә алып чыгып башкарыр алдыннан сүзләренең дөреслеген тикшертер өчен Габделхак хәзрәткә телефоннан шалтыраткан чакларым еш булды. Хәләл җефете Кәүсәрия ханым да һәрвакыт йомшак итеп, яратып хөрмәт белән сөйләште. "Уңайсызлыйм инде, мәшәкатьлим..." – дип читенсенеп кенә сүз башласам, алар тарафыннан: "Гел шалтыратыгыз, мәшәкатьлим дип уйламагыз", – дигән сүзләр генә ишеттек.

Яңа фатирга күчкәннән соң Коръән укырга да Габделхак хәзрәтне чакырдык. Ул безгә квартирыбыз белән котлап иң зур бүләк – Коръән китабы алып килгән иде. Мәҗлестә катнашкан туганнарга, якыннарга абруй иясенең догасын ишеттерү, бергәләп вәгазен тыңлау куанычлы бер вакыйга булып истә калды. Тирән гыйлеме һәм тел байлыгы, сөйләү осталыгы, ипле гәүдә-кул хәрәкәтләре, фәһемле карашы аша "вәгазь" сүзен фәкать тискәре мәгънәдә генә кабул итәргә өйрәнгән ничә буын инсанга Габделхак хәзрәт бу сүзнең чын эчтәлеген төшендерде. Бу вәгазьләр тормыш дәресләре, дөрес тормыш рәвеше аша ахирәткә әзерләнү дәресләре иде. Һәр җөмләсе алтынга тиң иде аның.

***Зөһрә СӘХӘБИЕВА-БИГИЧЕВА,***
***фольклорчы-җырчы,***
***Татарстанның халык артисты***

# БИК ХИКМӘТЛЕ БӘЙРӘМ

**Корбан бәйрәме көнендә барча мөселманнарның калебе-күңеле дуслык, туганлык, сөю, хөрмәт, кызгану, бер-береңә миһербанлык һәм шәфкать хисләре белән тула.**

Ул көнне нәфрәт һәм ачулар юкка чыга, дошманлык һәм үпкә хисләре бетә. Ата-ана һәм балалар, туганнар һәм дус-ишләр, күршеләр һәм хезмәттәшләр - һәммәсе дә бер-берсен изге бәйрәм белән тәбрик итә.

Корбан гаете Зөлхиҗҗә аеның 10 нчы көненә туры килә. Бу мөбарәк көндә мөселманнар таңнан торып, госел коенып, авызларын пакьләп, яхшы киемнәр киеп, хушбуй сөртеп, җәмәгать булып мәчеткә гает намазын укырга бара. Гаеткә барганда юлда туктап, тәкбир тәшрик ("Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, ләәә иләәһә илләллаһу уәллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр үә лилләәһил хәмде"), ягъни Аллаһ бөек, Аллаһ бөек, бөек Аллаһтан гайре Илаһ юктыр, Аллаһ бөек һәм Аллаһка мактау булсын дип әйтү - сөннәт, ягъни сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәламнең гадәте. Гает намазыннан соң, һәрбер хәлле мөселманга корбан чалып, җәмәгатьләрен һәм килгән кунакларын һәм күршеләрендә булган фәкыйрьләрне хөрмәт кылу важиб, ягъни тиешле.

Бу изге көндә күк капуслары ачык була, барлык фәрештәләр Аллаһтан адәм балаларының гөнаһларын кичерүне сорап, изге тәсбихтә булалар. Бу изге таңда мәчет манараларыннан әйтелгән азан, кылынган изге гамәлләр хөрмәтенә Аллаһ рәхмәте белән галәм изге нур белән тула.

Корбан бәйрәменнән алдагы көн, ягъни Зөлхиҗҗә аеның 9 нчы көне - Гарәфә көне дип атала. Бу көндә хаҗ гамәлләре кылына һәм бөтен дөньядан җыелган берничә миллион хаҗилар Гарәфә көнендә дога һәм гыйбадәттә була. Корбан бәйрәменең тарихына күз салыйк әле. Ибраһим галәйһиссәлам үзенең нәзерен үтәргә, ягъни Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен улын бугазлыйм дип торганда, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, Җәбраил фәрештә бер куй китереп, шуны корбан итеп чалырга куша һәм "Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр" дип әйтә. Ибраһим галәйһиссәлам тәкбирне ишеткәч: "Ләә иләһә илләллааһу үәллаһу әкбәр", - ди һәм аннан соң Исмәгыйль галәйһиссәлам болай дип өсти: "Аллаһу әкбәр үә лилләәһил хәмде". Хәзер мөселманнар бу сүзләрне Гарәфә көнендә һәм Корбан гаете көннәрендә һәрбер фарыз намаздан соң кабатлый. Ибраһим галәйһиссәлам улын азат кыла һәм Җәбраил фәрештә алып килгән куйны чала. Шул вакыттан бу йола безгә бәйрәм булып керә.

# ҮКСЕЗ БАЛА АСРАСАК...

## Ятимнәр белән эшләү – мөселман оешмаларының төп бурычы

**Илебездә 650 меңнән артык ятим бала бар. "Дима Яковлев законы" кабул ителгәннән соң, ятимнәр белән эшләү алгы планга чыкты.**

Билгеле булганча, Дима Яковлевны 2008 нче елда Америка гражданнары уллыкка ала. Беренче карашка, уңышлы гаилә, эти кеше – консалтинг фирмасының башкарма директоры. Ләкин, аларда ярты ел яшәгәннән соң, бервакыт баланы машинада онытып калдыралар, 9 сәгатьне 32 градус эсседә үткәргәннән соң, ул үлә. Америка законнары буенча, этисенә моның өчен 10 ел төрмә янаса да, суд аны аклый.

Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы бу эшнең кире каралуын таләп итте. 2008 нче елның декабрендә РФ Тикшерү комитеты, баланың үлү сәбәпләрен һәм уллыкка алынуының законга туры кил-килмәвен ачыклау өчен, җинаять эше кузгатты.

"Дима Яковлев эше" буенча тавыш чыкканнан соң, җәмәгатьчелеккә мондый очракның беренче генә булмавы ачыклана. Америка гражданнарының Россиядән уллыкка алган күп кенә ятим балалары яңа гаиләләрендә җәберләүләргә дучар була, кайбер очракларда алар үлә дә икән. Бу гауга нәтиҗәсендә, 2012 нче елның ахырында, РФ Дәүләт Думасы тарафыннан Америка гражданнарына Россиядән балаларны уллыкка бирүне тыючы "Дима Яковлев законы" кабул ителде. 2012 нче елның 28 нче декабрендә РФ Президенты В.Путин аны имзалый һәм ул 2013 нче елның 1 нче гыйнварыннан гамәлгә дә керде.

Бүгенге көндә Россиядә 650 меңнән артык ятим бала бар, бу – бик тә зур сан, XX гасырның авыр 30 нчы елларына караганда да күбрәк. Шул ук вакытта, Россиядә бары тик 13 мең гаилә генә ятим балаларны үзләренә алырга тели (алар рәсми рәвештә уллыкка алу чиратында тора). Бары тик 13 кенә мең... Кайбер гаиләләр берничә бала алырга әзер булган очракта да, йөзәр мең бала әти-әни назын күрмичә балалар йортларында калачак. Бу – җәмгыятебез өчен хурлык.

*(Ахыры 6 нче биттә.)*

# УҢ КУЛ БИРГӘННЕ СУЛ КУЛ БЕЛМӘСКӘ ТИЕШ




**Татарстан мөселманнарының Диния нәзарәтенең хәйрия һәм социаль булышлык күрсәтү бүлеге һәрдаим мохтаҗларга, үксез-ләргә ярдәм итеп тора. Аның җитәкчесе *Ләйсән Дәүләт-шина* белән очрашып, бүлек эшчәнлеге белән якыннанрак таныштык.**

**- Сез җитәкләгән бүлек эшенең төп юнәлешләре нинди?**

- Без үзебезнең бурычыбызны мохтаҗларга булышуда күрәбез, бу һәр мөселманның бурычы. Төрле акцияләр уздырабыз, ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне һәм аларга рухый, финанс яки башка яктан булышырга теләүчеләрне эзлибез.

**- Ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне әле эзләргә дә туры киләмени?**

- Беләсезме, мохтаҗ кешеләрнең күбесе тыйнак тормыш алып барырга тырышалар, үзләренә игътибар җәлеп итмиләр. Нәкъ менә шундый гаиләләрне табарга кирәк, һәм без табабыз да. Тормыш хәзер авыр, еш кына картлар һәм күп балалы гаиләләр авыр хәлдә кала. Яңа уку елы алдыннан без "Баланы мәктәпкә әзерлә" дигән чара үткәрдек, балаларга мәктәп кирәк-яраклары, букчалар бүләк иттек. Без 60 гаилә балаларын уку елына әзерли алдык.

**- Без сез үткәргән чараларда волонтёрларның да актив катнашуын беләбез, әлбәттә, Диния нәзарәте хезмәткәрләре генә бу кадәр эшне башкарып чыга алмас иде.**

- Эш шунда ки, без Диния Нәзарәтенең волонтёрлар белән нык элемтәдә торучы яшьләр бүлеге белән берлектә эшлибез. Балалар йортындагы инвалид балалар белән үткәргән чараларда волонтёрларның роле бик зур. Алар булышлыгы белән без инвалид балаларны курчак театрына, дельфинарийга, зоопаркка алып бара алдык. Яңа килгән волонтёрларга без андый балалар белән ничек аралашырга, үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеген һәм ничек итеп күңел төшенкелегенә бирелмәү турында аңлатабыз.

**- Чыннан да, ятим һәм мөмкинчелекләре чикләнгән балалар белән эшләү зур рухый көч таләп итә. Сез стресс белән ничек көрәшәсез һәм ничек тыныч булып кала аласыз?**

- Башта психологик яктан бик авырга туры килде. Өйгә кайткач та сабыйлар йортында күргәннәр искә төшә иде. Бу хәлдән чыгарга кирәк, шул очракта гына приюттагы балалар белән элемтә урнаштырып, нәтиҗәле эшләп була. Бу балаларның миңа барлык хатын-кызларга да эндәшкән кебек "әни" дип түгел, ә "Ләйсән" дип эндәшүләреннән дә аңлашыла. Балалар белән без бер-беребезгә шатлык, күтәренке күңел бүләк итәргә өйрәндек, дуслаштык, телефон номерларыбызны алмаштык. Алар безгә шалтыратып, хәлләребезне сорашалар, үтенечләрен әйтәләр.

**- Сез күп кенә чаралар үткәрдегез, шулар арасыннан күңелегездә калганы бармы?**

- "Апрель" рабилитация үзәгендәге балалар һәм аларның ата-аналары өчен табигать кочагында уздырган Сабантуй исемдә. Сабантуйга шулай ук Дәрвишләр бистәсендә урнашкан балалар йортында тәрбияләнүче балалар һәм аларның тәрбиячеләре чакырылган иде. Балалар бергәләшеп уйнады, күңел ачты, ата-аналар белән тәрбиячеләр учак ягып, пылау пешерде, концерт карады - һәркем проблемаларын онытып, чын күңелдән ял итте. Бу Сабантуйдан соң без бик күп җылы сүзләр ишеттек, бигрәк тә ата-аналар рәхмәт укыды.

**- Мондый чаралар үткәрү финанслар таләп итә. Сезгә кем булыша?**

- Без даими рәвештә химаячеләр (спонсорлар) эзлибез, хатлар язабыз һәм аларны төрле оешмаларга җибәрәбез. Кайчак спонсорлар безне үзләре таба. Еш кына бу кешеләрнең үзләрен белгертәсе килми, уң куллары биргәнне сул куллары белмәскә тиеш дигән принцип буенча эш итәләр. Бу бик күркәм гамәл.

**- Эшегездә нинди кыенлыклар белән очрашасыз?**

- Әлбәттә, барлык киртәләрне дә үтеп була, Аллаһы Тәгалә булышлыгы белән җиңә алмаслык кыенлыклар юк. Мәсәлән, кайвакыт балалар белән эш итүче оешма җитәкчеләре безне хиҗапларда күреп, балалар арасында дини пропаганда алып барырбыз дип куркуга калалар. Ләкин бергәләп эшли башлагач, киеренкелек юкка чыга. Дөрестән дә, без хәлебездән килгәнчә булышабыз, ә дәгъвәт өчен Диния нәзарәтендә махсус бүлек бар. Ә мөселман булуыбызны яшермәвебезнең сере шунда: моны белеп алар ислам диненә һәм мөселманнарга карашларын уңай якка үзгәртерләр дип өметләнәбез.

Без Казандагы Балалар хосписы белән берлектә эшләргә җыенабыз, анда шулай ук намаз уку өчен бүлмә дә ачылачак. Моннан тыш, "Ярдәм" реабилитация үзәгендә хатын-кызлар өчен фитнес-клуб ачмакчы булабыз. Шулай ук картлар йортлары белән эшләргә дигән ниятебез дә бар. Ә Корбан бәйрәмендә исә балаларның кул эшләре сатыла торган ярминкә оештырырга җыенабыз, җыелган акчаларны Балалар хосписына, "Апрель" реабилитация үзәгенә һәм балалар йортларына тапшырачакбыз. ДРКБның онкогематология бүлегендә дәваланучы балаларга бәйрәм акциясе дә уздырачакбыз. Ата-аналар һәм балалар өчен корбан итеннән ашлар, пылау куелган бәйрәм табыны әзерләнәчәк, балаларга тәмле бүләкләр таратылачак.

**- Волонтёр булырга һәм сезгә булышырга теләгән кешегә кая мөрәҗәгать итәргә?**

- Ярдәмчеләр безгә һәрвакыт кирәк. Алар +7 (834) 258 57 21 телефоны буенча шалтыратсыннар яки Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йортка, безнең бүлеккә килсеннәр иде.

*Әңгәмәдәш -*
**Нурия ГЫЙБАДУЛЛИНА**



# "Бөтен дөнья малын... бер шәкертнең авызына каптырыр идем"

Адәм баласы үзенең җанын-рухын иман белән ныгытса, тәнен ураза белән чистарткан булса, аңа шулай ук үзенең хәләл көчләре белән тапкан малын да пакьләү фарыз ителде. Аллаһы Тәгалә "Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 277 нче аятендә безгә шундый бер нәсыйхәтен җиткерә:

إنَّ الَّذِينَ آمَنُواْ وَعَمِلُواْ الصَّالِحَاتِ وَأَقَامُواْ الصَّلاَةَ وَآتَوُاْ الزَّكَاةَ لَهُمْ أَجْرُهُمْ عِندَ رَبِّهِمْ وَلاَ خَوْفٌ عَلَيْهِمْ وَلاَ هُمْ يَحْزَنُونَ

*"Иман китереп изге гамәлләр кылучы, намазларын укып зәкятләрен бирүче мөэминнәрнең әҗере Раббылары хозурында. Аларга ахирәттә курку һәм көенү булмас"* (Ногмани тәфсиреннән).

Зәкят бирү өчен кулыбыздагы мал, байлык нисаб күләменә җиткән булырга тиеш. Нисаб ул - байлыкның билгеле бер күләмгә җитүе. Малы нисаб күләменә җитмичә зәкят фарыз булмый. Зәкят кыйммәтле әйберләрдән, җанлы малдан һәм иген уңышыннан бирелә.


Кыйммәтле әйберләргә - кассадагы яки башка җирдә саклана торган акча, кыйммәтле кәгазьләр (вексель), алтын-көмеш әйберләр, бәллүр савыт-сабалар, стенадагы келәм, картиналар, сәүдә малы керә. Шуларның суммасы 84 грамм алтын бәясенә җитеп, бер ел дәвамында тотылмыйча сакланса, шул суммадан 2,5 % күләмендә зәкят түләнергә тиеш. 84 грамм алтын бәясе бүгенге акча белән якынча 120 мең сум тирәсе була. Зәкятнең икенче төре җанлы маллардан бирелә. Зәкят чыгарырлык нисаб: сарыклар - 40 баш, сыерлар - 30 баш, дөя - 5 баш. Терлек саны шуңа җитсә, зәкят чыгару тиешле була.

Зәкят кырда, бакчада үсә торган игеннәрдән, җимешләрдән дә чыгарылырга тиеш. Элек-электән әти-әниләребез, әби-бабаларыбыз көз айлары җиткәч, җыеп алынган уңыштан гошер сәдакасы бирә иде. Әлхәмдүлилләһ, бакчаларыбыздагы уңышларны түкми-чәчми җыеп алдык. Күпләребез инде авылларга кайтып бәрәңгеләрен дә алып килде. Без һәрвакытта да Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләнең биргән нигъмәтләренә шөкрана кылырга тиеш, чөнки бер Ул гына бирүче, безне нигъмәтләндерүче.

Нәрсә соң ул гошер? Бу гарәп сүзе "уннан бер өлеш" дип тәрҗемә ителә.

Димәк, без җирдә яңгыр суы белән үскән уңышның уннан берен (үзең су сибеп үстергәннең - егермедән берен) фәкыйрьләргә бирергә тиеш. Әгәр дә кеше гошер бирмәсә, үзе үстереп ашаган ризыгының һәр унынчы кисәге (чөнки ул мохтаҗлар өлеше) хәрәм була.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам бер хәдисендә:



*"Әгәр дә кешеләр үлчәүдә хыянәт итсә - тормышларында авырлык күрер, азанга игътибар итмәсә - тынычлык тапмас, тиешенчә (Аллаһ кушканча) киенмәсә (гаурәтләрен капламаса яисә зинаны ачыктан-ачык кылса) - Аллаһы Тәгалә аларга күз күрмәгән, колак ишетмәгән авырулар җибәрер, тиешле зәкят-гошерләрен бирмәсә - яңгырны вакытында яудырмас (яңгыр яуса да, үсемлек-хайваннар хакына булыр)"*, - дигән.

Икенче хәдис-шәрифтә: *"Әгәр дә өммәтем гадел булса, зәкят һәм гошер сәдакасын түләүдән туктамаса, аңа хәвеф-хәтәрләр төшмәс. Шулай эшләмәгән очракта, корылык һәм ачлык белән сыналачаклар"*, - диелә.

Бу дөньяда адәм баласы мал-мөлкәте турында сөйләгәндә: "Үзем таптым, үзем тырышлык куйдым, эшләдем", - ди, мәгәр, эшләсә дә, бирүчесе Аллаһ Раббыбыз икәнлеген онытып җибәрә. Аллаһы Тәгалә үз дөньясы белән генә яшәгән, Раббыбыз биргәннәрдән өлеш чыгармаган бәндәләр хакында "Әли Гыймран (Гыймран гаиләсе)" сүрәсенең 180 нче аятендә болай ди:

وَلاَ يَحْسَبَنَّ الَّذِينَ يَبْخَلُونَ بِمَا آتَاهُمُ اللّهُ مِن فَضْلِهِ هُوَ خَيْرًا لَّهُمْ بَلْ هُوَ شَرٌّ لَّهُمْ سَيُطَوَّقُونَ مَا بَخِلُواْ بِهِ يَوْمَ الْقِيَامَةِ وَلِلّهِ مِيرَاثُ السَّمَاوَاتِ وَالأَرْضِ وَاللّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ

*"Рәхмәт итеп Аллаһ биргән малда саранлык кылучы кешеләр уйламасыннар саранлыклары үзләренә файда дип. Бәлки саранлыклары үзләренә начарлыктыр, саранлык белән җыйган маллары тиздән Кыямәт көнендә муеннарына чорналыр. Җирдәге вә күкләрдәге байлык Аллаһныкы бит һәм Аллаһ сезнең кылган эшләрегездән хәбәрдар"* (Ногмани тәфсиреннән). Менә бу аять саран кеше хакында инде.

Зәкят чыгарырга малыбыз җитмәсә дә, гошер сәдакасын бирү күпләребезнең хәленнән килә. Аны кемгә тапшыру да әһәмияткә ия. Аллаһы Тәгалә "Тәүбә" сүрәсенең 60 нчы аятендә болай ди:

إِنَّمَا الصَّدَقَاتُ لِلْفُقَرَاء وَالْمَسَاكِينِ وَالْعَامِلِينَ عَلَيْهَا وَالْمُؤَلَّفَةِ قُلُوبُهُمْ وَفِي الرِّقَابِ وَالْغَارِمِينَ وَفِي سَبِيلِ اللّهِ وَابْنِ السَّبِيلِ فَرِيضَةً مِّنَ اللّهِ وَاللّهُ عَلِيمٌ حَكِيمٌ

*"Сәдакалар - фәкыйрьләргә, мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкят җыючыларга вә зәкят өчен исламга күңелләре өлфәт хасыйл иткән кешеләргә: тоткында булган кешеләргә, бурычын түләргә көче җитмәгән бурычлы кешеләргә, ислам дине өчен Аллаһ юлында һәм малсыз калган мосафирларгадыр, шул күрсәтелгән урыннарга бирмәк Аллаһтан фарыз ителде. Аллаһ белүче вә хөкем итүче"* (Ногмани тәфсиреннән). Югарыда санап кителгән җирләргә биргәндә генә аның әҗере була. Җыеп алынган уңышны бер генә кешегә бирсәң, аның череп-бозылып исраф булуы бар. Шуңа күрә, күп кенә дин галимнәре раславынча, аны мәдрәсәгә бирсәң яхшырактыр. Рәсүлебез галәйһиссәламнең сәхабәсе Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде) бер вәгазендә сәхабәләргә шундый сүз җиткерә: "Бөтен дөнья малын бер кашыкка тутырып кулыма бирсәләр, мин аны динне өйрәнүче бер шәкертнең авызына каптырыр идем". Шулай итеп, хәтта Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде) дә гошер малын мескен-мохтаҗларга бирү хакында түгел, бәлки шәкертләргә тапшыру турында аңлатып китә. Бу, әлбәттә, безгә зур үрнәк.


***Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә "Зәкят" хәйрия фонды эшләп килә. Аның адресы: Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт. Зәкяткә кагылышлы барлык өстәмә мәгълүматларны шуннан алырга мөмкин.***

# АЛЛАҺКА ЯКЫНАЙТУЧЫ ГАМӘЛЛӘР

## Хаҗ кылу

Хаҗның иҗтимагый тормышта әһәмияте әйтеп бетергесез. Ул изге Мәккә-и Мөкәррәмә вә Мәдинә-и Мөнәүвәрә шәһәрләрендә кылына. Әлеге калаларның бәрәкәтле туфрагында сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд (с. г. в.) эзләре дә саклана, аның тавышы да ишетелә сыман. Биредә аңа вәхи (хәбәр) килгән, монда аның сәхабәләре яшәгән. Рауза-и Мөтаһһәра, Бәдер, Үһүд, Хандакъ, Сәүр, Хира, Нур, Куба, Җәннәтүл-Бәкыгъ кебек изге урыннар белән танышу хаҗиларга "гасры сәгадәт"тә ("бәхетле чор"да) яшәгәндәге кичерешләрне хәтерләтә кебек.

Без яшәгән шушы фаный дөньяда һәркем үз алдында торган максатка таба хәрәкәттә. Һәр адәм баласы, үзенең хакыйкый асылын эзләп, аңа кайту юлларын эзли. Алар барысы да галәмнең табигый юнәлешендә хәрәкәт итеп, һәрдаим Аллаһы Тәгаләгә якынаерга тели. Шушы эзләнүләр аңа изге сәфәр - хаҗ кылуны йөкли. Бу һәр мөселман өчен фарыз булган биш гамәлнең иң мәртәбәлесе дип санала. Аның төп максаты - Аллаһ ризалыгы белән җәннәткә керү вә Аның дидарын күрү бәхетенә ирешү. Хаҗ ул - Аллаһка карата үзеңнең хәләл малың һәм җисемең белән гыйбадәт кылу. Сәфәр вакытында хаҗилар ислам диненең газиз үзәге, җир йөзенең йөрәге булып саналган изге Кәгъбәтулланы күрә. Шушы "кара ташның" тарту көченә буйсынып, миллионлаган мөселман аны тәваф кыла. Әлеге манзара җиде кат күкләрдәге "Бәйт-и Мәгъмүр" тирәли фәрештәләрнең бөтерелүенә тиң. Кара ташка, ягъни "Хәҗәрүл-әсүәд"кә сәлам бирү ул - гыйбадәттә кыйблага юнәлү генә түгел, бәлки шушы урыннарның илаһи галәмәтләренең асылына төшенү дигән сүз.



Хаҗ кылганда бөтенесе дә ап-ак кәфенлектәй ихрамга төренеп, ахирәткә күченгәнче үк үлем хәлен кичергәндәй бакый дөньяның ишеген шакыйлар сыман. Бу мизгелдә кылган гөнаһлар өчен үкенү вә изге гамәлләр өчен Хак Тәгаләнең рәхмәтенә ирешү шатлыгы иң югары ноктага җитә. Бу чакта һәр кеше хаҗдан соң гөнаһлы гамәлләргә якын килмәскә дип үзенә сүз бирә. Әгәр дә хаҗи ихлас йөрәктән тәүбә кылып ихрамнан чыкса, сабый бала кебек гөнаһсыз була.

## Гарәфә тавында тору (вакфа)

Бер урынга ап-ак күбәләктәй бихисап кешеләрнең Гарәфә тавында җыелып басып торуы, мәхшәр көнне адәм балаларының гомер буе ниятләре һәм кылган гамәлләре өчен Аллаһ каршында җавап тотарга җыелуын хәтерләтә. Гарәфәдә җыелган кешеләр үзләренең гөнаһлары өчен шушы рәхимсез җиргә җәннәттән куылган Адәм (г. с.) вә Хәүә (р. г.) халәтен кичерәчәк. Гарәфә тавында кыйблага юнәлеп, "Җәбәлүр рахмәһ" (Рәхмәт тавы) дигән урында Аллаһы Тәгаләгә ялварып кылынган дога, адәми зат өчен хәерле булып, Җәнабел Хак тарафыннан кабул ителәчәк. Чөнки әлеге дога иң мөбарәк сәгатьтә илаһи бүләк булачак.

## Шайтанга таш ату

Аллаһ юлында үз-үзеңне корбан итү һәм Аның рәхмәтенә ирешергә ниятләгән кешегә каршы шайтанның тырышлыгы үзенең эзлеклелеге һәм даимилеге белән аерылып тора. Шуңа да шайтанга таш ату - нәфескә һәм шайтанга каршы аяусыз көрәшне чагылдыручы Олы җиһадның тышкы билгесе. Шайтанга томырылган һәр таш Аллаһ зикере булып нәфес һәм шайтан уенына кылыч белән кадаган кебек була.

## Кәгъбәне тәваф кылу

Кәгъбә тирәли әйләнеп йөрү - Аллаһка таба хәрәкәт итүнең чагылышы булып тора. Тәваф тәүхиднең асыл мәгънәсен аңларга ярдәм итә. Әлеге әйләнеп йөрү галәмдәге күк җисемнәренең - планеталар, йолдызлар, галактикаларның хәрәкәтен кабатлый сыман. Бу хәрәкәт "Без барыбыз да Аныкы һәм Аңа кайтачакбыз" дигән хакыйкатьне чагылдыра. Тәваф вакытында Аллаһка таба юнәлү йөрәгең, зиһенең, телең һәм бөтен әгъзаларың белән дә хәрәкәтләнүгә кайтып кала. Аллаһны зикер кылу һәм Аңа якынаюның тагы бер билгесе Кәгъбәтулла булып санала. Тәваф - җир йөзендәге бөтен нәрсәне колачлый торган символик мәгънәгә ия. Ул Аллаһка таба хәрәкәт итүнең билгесе. Йөгереп бару, ягъни сәгый кылу - кабаланып үзеңнең Хак Тәгаләңне эзләүне чагылдыра.

## Корбан чалу

Корбан чалу - хаҗдагы фарыз гамәлләрнең берсе. Ул Аллаһ юлында кирәк чакта үзең өчен иң газиз нәрсәдән дә ваз кичәргә, аны корбан итәргә әзер булуыңны дәлилләүче гамәл. Моның иң күркәм мисалы булып Аллаһка якынаю юлында үзенең сөекле улын Исмәгыйльне (г.с.) корбан итәргә әзер булган Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрнең үрнәге санала.

## Аллаһны зикер кылу

Аллаһка гыйбадәт кылуның бөтен гамәлләренең асылы - зикер булып санала. Хаҗ кылганда зикер тулы куәткә тавыш белән дә, җәмәгать белән бергә дә әйтелә. Кешеләрнең йөрәкләре вә телләре бер үк халәттә булып һәм бер үк мәгънә илә Аллаһка "Ләббәйкә Аллаһүммә Ләббәйк!" дип тәкрарлый. Хаҗ вакытында Кәгъбә тирәли зикер әйтеп тәваф кылган мөселманнар Аллаһ янында бөтерелеп әйләнүче һәм аны олылап мактаучы планеталарны хәтерләтә. Гайшә (р. г.) сүзләренә карaганда, Рәсүлебез (с. г. в.): "Кәгъбәтулланы тәваф кылу, Сафа һәм Мәрвә арасында йөгереп үтү, шайтанга таш ату фәкать Аллаһны зикер итү өчен гамәлгә куелды", - дип әйткән. Хаҗ гамәлләре барысы да, нигездә, Аллаһны зикер итү булып санала; Аллаһы Тәгаләне бөтен дөньяда табынырлык бердәнбер илаһи зат итеп, Аның бөеклеген, көдрәтен вә куәтен таныту ул.

# ҮКСЕЗ БАЛА АСРАСАК...

*(Ахыры. Башы 4 нче биттә.)*

Йөзәр мең бала һәм гарип-гораба беркемгә дә кирәк булмаган җәмгыять сәламәт дип исәпләнергә хаклымы? Бу балалар үз тормышларында ата-ана тәрбиясе, ата үгет-нәсыйхәте, ана назы һәм әби-бабай яратуын күрми.

Әгәр дә без бөтен ятим һәм инвалид балаларны гаиләләребезгә алып бетерә алмыйбыз икән (ә моңа омтылырга кирәк), гамәлдәге балалар йортларында уңайлы шартлар тудырырга кирәк. Һәр бала да игътибар үзәгендә булсын өчен, балалар йортлары күбрәк төзелергә, аларда эшләүче хезмәткәрләрнең саны артырга тиеш.

Барыбызга да билгеле булганча, күпчелек ятим бала, кызганыч, эти-әнисе язмышын кабатлый һәм җинаятьчелек юлына баса, наркомания афәтенә бирелә. Мондый хәл – бу балаларның язмышы өчен җаваплы булган мәгариф системасының камил булмавы нәтиҗәсе. Балаларны, күп очракта, ике каршылык боза: аларга карата тәрбиячеләрнең начар мөгамәләдә булуы, интернатларда һәм балалар йортларында яшәү шартлары кыен булу (бу – балаларда асоциаль, ягъни җәмәгатьчелеккә каршы, иҗтимагый булмаган холык формалаштыра) яки профессиональ булмаган, мөстәкыйльлеккә өйрәтми торган, кешегә салынып яшәргә күндерә торган кайгыртучанлык.

Беренче пункт буенча шуны әйтергә кирәк: барлык ятим балалар да кимсетелгән хәлдә яши. Әлбәттә, барлык яшүсмерләр дә төрледән-төрле тормыш каршылыклары белән очраша, ләкин ата-ана тәрбиясендә булган балалар мәктәп яки урам проблемаларыннан соң өйләренә кайтып, туганнарыннан ярдәм сорый, юаныч ала ала. Аларның матди һәм рухый терәкләре бар. Ятим балалар исә көне буе яшьтәшләре һәм тәрбиячеләре күз алдында, аларның сыеныр урыннары юк.

Икенче пунктка килгәндә, аның да әһәмияте бик зур. Ятим балалар белән эшләгәндә, үсеп җиткәч, олылардан ярдәм көтеп ятмыйча, үз көчләре белән яши башласыннар өчен, аларны мөстәкыйль тормышка өйрәтү лазем.

Россия ятимнәре белән килеп туган бу хәлдә дини оешмалар да, шул исәптән мөселман оешмалары да үз сүзләрен әйтергә тиешлеген ассызыклап тору кирәк микән? Илебез мөселманнары үз җаваплылыкларын тоеп яшәргә тиеш, чөнки моны динебез таләп итә. Андый җәмгыятьтә ятимнәр һәм балалар йортлары бөтенләй булырга тиеш түгел, аларның булуы – һәр мөселманга зур хурлык. Мөселман җәмгыятендә социаль җаваплылык хисе бик тә югары, шуңа күрә ятим калган балаларны туганнары яисә күршеләре үзләренә ала. Әлбәттә, безнең җәмгыятебез үзенчәлекле һәм моны истә тотарга кирәк. Шуңа да, хәзер мөселманнарның илебездәге бу зур мәсьәләне чишү юнәлешендә эшләүләре бик мөһим.

Мөселман оешмаларына һәм мөселман иганәчеләренә (хәйриячеләренә) рухый торгызылуга нигезләнгән балалар йортларын булдыру өчен зур көч куярга кирәк. Балалар психологик һәм матди ярдәмгә генә түгел, тулы рухый реабилитациягә дә мохтаҗ.

Мондый балалар белән эшләү – илебездәге мөселман институтлары (биредә бу сүз киң мәгънәдә – социаль структура элементын тәшкил итүче төшенчә буларак кулланыла. – **Ред.**) өчен стратегик юнәлеш. Шундый һәрбер бала белән эшләп, без аңа ислам дине кыйммәтләренә төшенергә ярдәм итәбез, мөселман җәмгыяте җылысын бүләк итәбез, аны төрле явызлыклардан коткарып калабыз, өммәтебез үсешен нygытабыз, алар арасыннан сәламәт, уңышка ирешкән һәм эш сөючән граждannar гына түгел, бәлки киләчәктә зур мөселман галимнәре, вәгыйзьләр (вәгазь сөйләү осталары) һәм имамнар үсеп чыгу өчен дә зур мөмкинчелекләргә ия булабыз.

*Илдар БАЯЗИТОВ,*
*Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль проектлар җитәкчесе,*
*мөфти урынбасары*

# Зирәк булыйк, кирәк булыйк әле

**Өлкәннәр ункөнлеге башланган көнне Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм социаль ярдәм күрсәтү бүлеге, «Ярдәм» илкүләм мөселман хәйрия фонды һәм Ярдәм мәчете бик күркәм бәйрәм үткәрде.**

Халкыбызның хөрмәтле, зирәк кешеләре чакырылган иде анда, Россиянең төрле төбәкләреннән килеп укучы күрмәүчеләр дә, республика һәм Казаныбыздагылар да катнашты. Кичә Коръән уку белән башланды. Аннары нәзарәтнең хәйрия һәм социаль ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Ләйсән Дәүләтшина җыелучыларга җылы тәбрикләү сүзләре юллады.

Кичәдә Россия ислам институты шәкерте Сәет Давытның мөнәҗәте күңелләрне рәхият дулкынына алып кереп китте. Мәчетнең күрмәүчеләр арасында үз системасы буенча бөтен Коръәнне ятлый башлаган, инде берничә җөзне белүчеләр төркеме булу аеруча шатландыра. Аллаһның рәхмәте бик киң шул! Кайсыларының моңлы итеп татар халык җырларын сузуы һәрберебезне тирән уйларга салды, ә язган шигырьләрен тыңлагач, кинәт кенә югалып калгандай буласың, бөтен саны төгәл булган, җете күрүче күзлеләр хакында фикер йөртеп, тирән уйларга чумасың. Ник Аллаһның безгә биргән бүләкләренең кадерен белмибез соң ә? Ник соң әдәпәхлак кануннарыннан читләшеп, кайберәүләр наркомания, фахишлек дигән коточкыч афәтләргә тарый? Бу бәйрәмдә без болар хакында да уйландык.





Әлеге очрашуны, гадәттәгечә, сәнгать әһелләре дәвам иттерде. Халкыбызның «Сөбханаллаһ» дип тыңларлык моң ияләре – Ринат Вәлиев, Руслан Баһадур кебек уллары барыбызны да ихластан ял иттерде. «Заречье» балаларга өстәмә белем бирү үзәгеннән «Бәрәкәт» ансамбле дә килгән иде. Геннадий Макаров җитәкчелегендәге әлеге ансамбльнең җырчысы Айгөл Җәләлиеваның чыгышы һәр күңелне тетрәтте. Очрашу мәҗлесен Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетының бик өметле, күркәм тавышлы шәкерте, Балтач районы егете Ирек Фатыйхов алып барды. «Аңа Аллаһның рәхмәте яусын, сәнгать-моң дөньясында уңышлар юлдан булсын», – диделәр бәйрәмгә килүчеләр.

Тагын шуны да искәртим әле. Ярдәм мәчетенең Тернәкләндерү үзәгендә кул эшләре белән дә шөгыльләнәләр икән. Вәсим Шәйхиев, Линда Габдрәшитова, Алия Хәйруллина, Алинә Галимоваларның иҗадый эшләрен күреп сокланмый мөмкин түгел иде.

...Әлеге бәйрәмне Өлкән-нәр көне димичә, Зирәкләр бәйрәме дип атавым бер дә юкка түгел. Зирәк булыйк, акыллы булыйк, җәмгыятебезгә файдалы кешеләр булыйк!

*Әлмира ҺӘДИЯ,*
*җәмәгать эшлеклесе*

# БҮГЕН КИЧКӘ МӘҖЛЕСКӘ...

**Соңгы вакытларда кайбер мөселманнар авызыннан мөселман йолаларын үткәрү турында тискәре фикер ишетергә туры килә. Мөселман яшьләре үткәргән мәҗлесләр хәтта көлке объектына әйләнә. Эш кайвакыт шуңа кадәр барып җитә, үз фикерләрендә аеруча үҗәтлек күрсәтүче кайберәүләр мондый мәҗлесләр үткәрүне исламга һәм аның нормаларына туры килми дип тәкрарлый.**

*Мәҗлес* борынгы гарәп сүзе, ул дөньяның бар мөселман халыклары телендә дә кулланылышка кергән. Ул үткәрелә торган чара буларак тәрҗемә ителә, бу чара вакытында кешеләр бергә җыелып, кемнедер тыңлый. Безнең якларда традицион рәвештә мәҗлес дип туганнар, дуслар, үзара якын кешеләрнең никах, исем кушу яки мәрхүмне искә алу өчен җыелышын әйтәләр. Татарларда мәҗлесләрнең бу төрләре мең елдан артык дәвам итә һәм аның нигезләре бик борынгы заманнардан ук килә. Мәҗлесләр үз нигезләре белән ислам иҗтимагый фикеренең бишеген тәшкил иткән.

Мондый мәҗлесләрдә Коръән укыла, Аллаһка мактаулар әйтелә һәм, иң мөһиме, вәгазь укыла. Нәкъ менә шул вәгазьләрдә мәҗлеснең чын асылы яшеренгән дә инде. Әгәр дә без, аның бөек мәгънәләрен аңлатмыйча гына, Коръән укыйбыз икән, бу мәҗлеснең уңай нәтиҗәсе азрак булыр иде. Мин шуның өчен дә мәҗлесләрне ислам иҗтимагый фикеренең бишеге дип атыйм, чөнки бу мәҗлесләрдә ислам шәхесе формалаша. Татарстанда гына да мәҗлесләрдәге вәгазьләрнең йогынтысы нәтиҗәсендә меңнәрчә кешеләр Аллаһ диненә килә.

Россиядә фетнә һәм дәһрилек чорында меңнәрчә гыйбадәтханәләр җимерелде, дин әһелләре үтерелде, юк ителде. Динле кешеләрнең күбесе эзәрлекләүләргә, репрессияләргә дучар ителде. Бу кадәр басымга түзеп тора алмыйча, үз иманнарын, үз ата-бабалары иманнарын компартия уйлап чыгарган ялган яңа инануларга алмаштыручылар да булды. Күпләр гыйбадәт кылудан, намаз укудан, ураза тотудан туктады. Коръән һәм хәдисләр теле онытылды. Әмма система халыктан бер әйберне – халыкның дини традицияләрен тартып ала алмады. Алар мәҗлесләрдә сакланып калды, ул мәҗлесләрдә Коръән укылды, хәдисләр сөйләнде, ислам һәм аның йолалары нәсыйхәт кылынды. Дәһрилекнең иң кискен чорларында да татарларның күбесе мәҗлесләрдән баш тартмады. Төрле сылтаулар белән, үз ниятләрен яшереп, алар мәҗлесләр үткәрүләрен дәвам итте, никахлар укыды, балаларын сөннәткә утыртты, яңа туган балаларга исемнәр кушты һәм, никадәр түбән төшерергә тырышмасыннар, Аллаһның дине, Аллаһның сүзе барыбер өскә калкып чыгачак, дип халыкка чын хакыйкатьне җиткерде.

Өлкән буын вәкилләре игелекле шул традицияләр рәвешендә тапшырып калдырган динебезне без дөрес кабул итеп алырга һәм алга таба үстерергә тиеш.

*Хәбир хәзрәт ХАНОВ,*
*Чирмешән мәчете имам-хатыйбы*

# БЕР ЕЛГАНЫҢ ИКЕ ЯРЫ

**“Мөселманнарның кыргый бер йолалары бар: кызлар җенси өлгергәнлек чорына җиткәч, аларны фаллос формасында эшләнгән махсус сынга утыртталар. Аннан соң, алар айга табыналар һәм кара ташны илаһлаштыралар. Ә аларның үзен Пәйгамбәр дип игълан иткән Мөхәммәдләре 1908нче елда үлгән”.**

Алдагы абзацта әйтелгәннәрнең барысы да ялган. Ләкин бу ялган – үзенә бертөрле ялган һәм бу ялганны исламга махсус тагалар. Өстәвенә, мондый ялганны еш кына үзләрен мөселман дип атаучы кешеләр тарата. Ап-ачык бер мисалда исламныкы итеп күрсәтелгәннәрнең чынлыкта берсенең дә исламныкы түгел икәнлеген күрсәтү өчен мин бу ялганнарның шаккатыргычларын махсус сайлап алдым. Үзләрен мөселман дип атаучы кайберәүләрнең каләмнәреннән һәм авызларыннан чыкканның һәрберсенең дә исламга катнашы юк.

Ләкин кайвакыт ялган алай ук күзгә бәрелеп тормый. Аның ялган икәнен аңлар өчен махсус белем таләп ителә. Бу принцип бер ислам өчен генә түгел, ә гыйлемнең теләсә кайсы өлкәсе өчен дә дөрес. Әгәр дә: «Декогеренция дулкынлы функциянең коллапсын фундалштыра”, – дип әйтсәләр, сезгә бу абракадабраны аңлау өчен квант физикасында бераз гына булса да мәгълүматлы булу кирәк. Ә мин физик түгел. Шуңа күрә дә бу өлкәдә теләсә нинди юк-бар сүз әйтүем ихтимал. Ләкин бу, предметларына мөнәсәбәтле булган өчен генә, профессиональ физиклар минем дилетант фикерләремне җитди кабул итәргә тиеш, дигәнне аңлатамы соң әле? Юк, әлбәттә. Физиклар өчен бу принцип – ап-ачык. Ә менә махсус әзерлеге булмаган кешеләрнең колакларына квант физикасы өлкәсендәге фәннигә охшаганрак мондый “токмач”ны мин чиләкләп коя алам.

Мин бу мисаллар белән гап-гади әйберләрне аңлатырга тырышам. Дөресен генә әйткәндә, моның белән шөгыльләнеп утыруы да уңайсыз. Ләкин, кызганыч ки, безнең халкыбыз арасында дин мәсьәләләрендә бик тиз юлдан яздырырга мөмкин булган кешеләр дә күп, чөнки күпләребез динне бик аз дәрәҗәдә дә белми шул әле. Сәләфиләр дип үз-үзләрен атаучылар: “Без ата-бабаларыбыз юлыннан барабыз” яки “Без сәләфиләр түгел, ә хәнәфиләр”, – дип әйтүчеләрнең алдашуын бик азлар гына аңларга сәләтле. Кайберәүләр өчен аларның бу сүзләре минем декогеренция турындагы “фикерләрем” кебек үк дөрес булып күренергә дә мөмкин.

Мондый очракта физик яки башка берәр белгеч нишләр иде? Ул теләсә нинди вөҗданлы галим әйтергә тиеш булган сүзләрне әйтер, ягъни акны – ак, караны – кара, дияр иде. Хәзерге ислам галимнәре алдында да, гомумән, битараф булмаган барлык мөселманнар алдында да шундый ук мәсьәлә тора. Алар Пәйгамбәрнең (с. г. в.) безнең халыкта йөзләрчә еллар буена сакланып килгән чын традицияләренең бернинди дә марыкый мутацияләргә дучар ителмәвен тели.

Ә традицияләр нәрсә соң ул? Кайберәүләр алар тулысы белән хәнәфи мәзһәбенә кайтып кала дип уйлый. Чынлыкта исә, хәнәфи мәзһәбе ислам хокукы мәсьәләләренә генә җавап бирә, ә аннан тыш әле исламның тагын да мөһимрәк өлеше – ислам илаһияте дә бар. Бу мәсьәлә буенча татарлар сөнни илаһият кысаларында булган ике агымның берсе – мәтуридилык тарафдары булган. Ислам әһле сөннәт вәлҗәмәгатьнең, ягъни Пәйгамбәр исламының гакыйдә (илаһият) мәсьәләләрен бары тик кануный ике мәзһәб: әшгари һәм мәтуриди мәзһәбләре генә чагылдыра. Безнең ата-бабаларыбыз борын-борыннан ук икенчесенең тарафдарлары булган. Бу турыда мәшһүр татар галиме Морад Рәмзи (1854-1934) менә нәрсәләр яза: “Татарларның юлына (мәзһәбенә) килгәндә исә, алар илаһияттә сөнни-мәтуриди, ә гамәлләрдә – хәнәфи булган. Бүгенге көнгә кадәр алар арасында марыкый бидгатьчеләр булмаган”.



Гамәлләрдә хәнәфи, ә илаһияттә мәтуриди булу – болар бер елганың ике яры шикелле. Ләкин, соңгы вакытларда татарлар арасында шундый кешеләр дә килеп чыкты, алар конъюнктур ниятләрдән чыгып, үзләрен хәнәфи дип атый, әмма иман мәсьәләләре буенча, безнең халык өчен (димәк, бар гомум кабул ителгән сөнни илаһият өчен дә) чит булган сектант карашларда тора. Вәлиулла хәзрәт Якупов алдауның бу юлын “хәнәфи мәзһәбе артына яшеренү тактикасы” дип атый иде.

Бу тактикадан, гадәттә, псевдосәләфиләр файдалана. Алар моны үзләренең чит илләрдәге остазлары кушуы буенча эшли. Мәсәлән, Ибне Баз: “Намаз укыган вакытта “Әмин” дип кычкырып әйтүне тәшереп калдырырга һәм кулларны өскә күтәрми калырга мөмкинме?” – дигән сорауга: “Әйе, әгәр дә кулларын өскә күтәреп, кычкырып “Әмин” дип әйтми торган кешеләр арасында булсагыз, күңелләрне берләштерү һәм кеше аларны игелеккә өнди, аларны өйрәтә һәм аларга туры юл күрсәтә алсын өчен, шулай ук сезгә дә бу эшләрне эшләми генә намаз уку өстенлеклерәк”, – дип җавап биргән (Әш-Шәех Ибне Баз фәтвасы. – Т. 29). Бүтәнчәләп әйткәндә, Ибне Баз фикере буенча, мөселманнарга псевдосәләфи гакыйдәне тарату мөмкинлегә алыр өчен, намаз укыган вакытта хәнәфи булып кыланырга кирәк.

Шуңа күрә дә, псевдосәләфиләрнең берәрсе сезгә: мин безнең халык традицияләрен һәм Пәйгамбәребез Сөннәтен саклыйм, чөнки мин хәнәфи мәзһәбе тарафдары, дип әйтсә, бу ярымхакыйкать кенә була, аңа ышанмагыз, чөнки аның бу сүзләре артында зур ялган ята. Алар күзгезгә төтен җибәреп, алдап, ялган сәләфиләр рәтенә ияртер өчен сезнең ышанычыгызны ауларга тырыша.

Аларның үзләрен сәләфиләр дип атаулары да тактиканың бер төре, ул да беләме аз мөселманнарны ялгышуга китерә. Ләкин, ул чынлыкка туры киләме соң? Сәләфиләр алар, мөбарәк Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның рәхмәте вә сәламе булса иде) чорыннан башлап мөселманнарның беренче өч буыны: сәхабәләр, табигыйннар, тәбгы табигыйннар. Алар үзләренә әнә шул атаманы тагарга тели. Сәләфи булу дигән сүз ул мөселманнарның беренче өч буынының иң яхшы кешеләренең дәвамчысы булуны аңлата. Алар Пәйгамбәрнең (с. г. в.) чын исламын безнең өчен саклап калып, аны тулысынча формалаштырган. Шундыйларның берсе, мәсәлән, имам Әбу Хәнифә булган, ул Пәйгамбәрнең (с. г. в.) сәхабәләре исән вакытта яшәгән, алар белән таныш булган, ягъни, ул табигыйннардан булган; аннан соң аның шәкертләре: Әбу Йосыф, Зөфәр, Мөхәммәд һәм башкалар, алар – тәбгы табигыйн буыны мөселманнары.

Үзләрен сәләфиләр дип атап, шулкадәр дә югары статуска дәгъва белдерүчеләр кем артыннан бара соң? XX гасырда яшәгән Ибне Баз, Ибне Госәймин һәм Албаниларга ияргән алар. Ялган сәләфиләр еш кына үз мәзһәбләрен Габделваһһаб һәм Ибне Таймиягә тоташтыра. Габделваһһаб – XVIII гасырда, ә Ибне Таймия XIII гасыр ахыры – XIV гасыр башында яшәгән.

Кайбер илләрдә ялган сәләфиләр үзләрен хәнбәлилекнең бер тармагы итеп күрсәтергә тырыша. Бусы да җирле традиция артына яшеренергә маташу гына. “Аларда үзләрен хәнбәли мәзһәбе тарафдары итеп күрсәтү гадәте бар иде”, – дип яза алар турында бөек шәех Ибне Әл-Габидин. Гәрчә, чынлыкта, шәйх Сәед Габдел-Латыйф Фуда билгеләп үткәнчә, псевдосәләфиләр алар “Әһле Сөннәт”тән читкә тайпылган кешеләр”. “Бу кешеләр үзләрен “әс-сәләфия” дип атый, – дип дәвам итә Сәед Габдел-Латыйф Фуда, – ләкин, чын сәләфиләрнең алар (“әс-сәләфия”) эшләгәнгә бернинди дә катнашлары юк. Чынлыкта исә, бу төркемнең үз мәзһәбләрендә, “әл-хәшәвия”, “әл-кәррамия” һәм надан яһүдиләрдән тыш, бернинди дә алдан килүче нигезләүчеләре (“сәләф” – алдан килүче, нигезләүче дигәнне аңлата) юк”.


Шуңа күрә дә, алда китерелгәннәрне исәпкә алып, үзләрен сәләфиләр дип атаучыларны, төгәлрәк итеп әйткәндә, үз атамаларын урлаучы узурпаторлар яки псевдосәләфи, я ялган сәләфиләр дип атау дөресрәккә күбрәк туры килә.

Безнең халыкны рухый яктан коткарып калу, шул исәптән, бу юньсез ялганны үз вакытында фаш итүгә бәйле. Безнең исламны дөрес тотуыбыз беренчел булып тора бит. Шуңа күрә ислам хокукы өлкәсендәге мәзһәбебезгә караганда, илаһият (гакыйдә) мәсьәләләрен аңлатуда тарафдарыбыз булган без ияргән мәзһәб билгеләүче булырга тиеш. Псевдосәләфиләр матур сүзләрне күп сөйли. Ләкин, әгәр дә алар ялган һәм монафикълык белән буталган икән, ул сүзләрнең нинди кыйммәте бар? Аллаһка шөкер, безнең халык арасында туры юлны күрсәтә алырлык кешеләр һаман да күбәя бара. Ул – хәнәфи һәм мәтуриди традицияләрендә сакланып, буыннан-буынга тапшырылып килгән мөбарәк Пәйгамбәребез (с. г. в.) юлы.

***Рөстәм БАТЫР,***
***Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары***



# ФӘКЫЙРЬ КЕШЕЛӘР КОРБАН ЧАЛА АЛАМЫ?



**СОРАУ.** ***Минем әби тыйнак кына яши, аның акчасы күп түгел. Әгәр дә моның өчен үзенең бар акчасын диярлек тотарга тиеш булса, ул корбан чалырга тиешме? Мин аңа акчалата ярдәм итсәм, аның чалган корбаны кабул буламы?***

**ҖАВАП.** Әгәр дә аз тәэмин ителгән, корбан чалу аның өчен ваҗиб булмаган кеше (нисаб мөлкәте булмаган фәкыйрь кеше) корбан чалу нияте белән берәр сарык сатып алса, ул моны үзе өчен ваҗиб гамәл дип исәпләгән итеп бәяләнә. Ягъни, бу гамәл гореф-гадәт буенча нәзер әйтелгән гамәл булып санала, чөнки, ярлы булуына карамастан, бу кеше корбан чалу өчен сарык сатып алса, "Заһиру-Риуәя" буенча, ул бу корбанны чалырга тиеш, чөнки, ул бу гамәле белән (ягъни сарыкны сатып алуы белән): "Мин бу сарыкны корбан итеп чалырга сатып алдым", - дип әйткән кебек була.

Әгәр дә фәкыйрь кеше корбан чалам дип нәзер әйткән икән, аңа бу корбан итен ашарга ярамый, ул аны бай кешеләргә дә таратырга тиеш түгел, ягъни, башкача әйткәндә, ул бу сарык итен бары тик фәкыйрь кешегә генә таратырга тиеш.

Фәтәвә әл-Һиндиядә шулай диелгән:

نَذَرَ أَنْ يُضَحِّيَ وَلَمْ يُسَمِّ شَيْئًا، عَلَيْهِ شَاةٌ وَلَا يَأْكُلُ مِنْهَا، وَإِنْ أَكَلَ عَلَيْهِ قِيمَتُهَا

Әгәр дә корбан чалам дип нәзер әйткән кеше, корбан чала торган малның нинди булуы (сарыкмы ул, сыер малымы һ. б.) турында берни дә әйтмәгән икән, бу вакытта, корбанга сарык чалу ваҗиб була, тик ул кеше бу сарык итен үзе ризык итеп кулланырга тиеш түгел. Әгәр дә сарык итен үзе ризык итеп кулланган икән, ул кулланган кадәр итнең бәясен фәкыйрьләргә бирергә тиеш.

وَأَمَّا فِي الْأُضْحِيَّةِ الْمَنْذُورَةِ سَوَاءٌ كَانَتْ مِنْ الْغَنِيِّ أَوْ الْفَقِيرِ فَلَيْسَ لِصَاحِبِهَا أَنْ يَأْكُلَ وَلَا أَنْ يُوَكِّلَ الْغَنِيَّ هَكَذَا فِي النِّهَايَةِ.

Нәзер буенча корбан чалган кешегә, аның бай кешеме, әллә инде фәкыйрь кешеме булуына карамастан, һичбер очракта да бу малның итен үзенә ризык итеп кулланырга һәм аны байларга таратырга ярамый ("Ән-Ниһәя" китабыннан).

***Чыганак: www.islam-today.ru***

**СОРАУ.** ***Мөселман үзенең улы, кызы, хатыны исеменнән корбан чалырга тиешме?***

**ҖАВАП.** Кешегә үзенең колы, үсеп җиткән улы өчен (әгәр дә ул балигъ булган һәм нисаб мөлкәткә ия булса, аның үзенә корбан чалу лазем) корбан чалу мәҗбүри түгел. Әгәр дә балигъ булмаган улының нисаб күләмендә (мөлкәтнең зәкят түли башлар өчен билгеләнгән минималь микъдары) мөлкәте бар икән, бу очракка карата ике төрле риваять яши. "Мохтәсар-Тахәви" шәрхендә: "Заһиру-Риуәя" буенча, бу ваҗиб гамәл дип исәпләнми.

**СОРАУ**. ***Гаиләдәге берничә кеше өчен бер корбан чалырга ярыймы?***

**ҖАВАП**. Бер сарык яки кәҗә бер кеше өчен генә исәпләнә, ә чалынган мал сыер яки дөя булса, бу корбан чалуда катнашучыларның саны җиде кешегә кадәр җитәргә мөмкин. Кешегә гаилә әгъзалары өчен корбан чалу мәҗбүри булып тормый.

**"Бәдәигүс-санәәигь" һәм "Китәәбүл-Үдъхийәһ" китапларыннан**

## Урта Пошалым мәчетен бергәләп төзик!

Хөрмәтле авылдашлар, якташлар, милләттәшләр һәм дин кардәшләр! Аллаһы Тәгалә кушып, Татарстан Республикасының Арча районы Урта Пошалым авылында мәчет төзелә. Халыкта, ил төкерсә, күл була, диләр. Әйдәгез, шушы саваплы эшне бергәләп башкарыйк! Күгебездә тагын бер изге ай калыксын!

Изге гамәлдә матди ярдәм кылырга теләүчеләр өчен, мәхәлләнең Россия Саклык банкындагы исәп-хисап счёты номеры: 42307810262165010034/ 48.

**Корр. счёты номеры: 20202810167000100679.**

Шулай ук, мәчет төзелешенә акчалата ярдәмне авылда (имам-хатыйбка яисә мәхәллә казначеена) калдырып китәргә дә була.

**Элемтә өчен телефон: 89178689729 (Рәшит Галләм).**

## "Мохтаҗларны тукландыр"

**"ЗӘКЯТ" хәйрия фонды Корбан бәйрәме алдыннан "Мохтаҗларны тукландыр" акциясе башлануын белдерә. Әлеге акция кысаларында фонд мохтаҗларга - авыру кешеләргә, инвалидларга, ялгыз картларга, толларга, ятимнәргә, шулай ук дини уку йортларына өләшү максатыннан, корбан тәкәләре сатып алу өчен акча җыя.**

**Корбанлык тәкәнең бәясе (терлекне чалу, эшкәртү ?әм таратуны да кертеп) алты мең сум.**

***Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт, 3 нче кат адресы буенча яки +7 (843) 225-33-22 телефоны аша мөрәҗәгать итә аласыз.***

**Интернетта сайтыбыз: www.zakyatrt.ru.**

**Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.**

## Үгетли белсәң – үгет...

**Ялгышкан вакытта кешегә дөрес үгет-нәсыйхәтләр биреп, аны туры юлга кертә торган дуслары булу бик мөһим. Имам Газзали (рәхимуллаһ): “Әгәр син кешеләргә чынлап та игелек телисең икән, син аны беркем дә күрмәгән вакытта, бергә-бер калып, аңа кисәтү һәм үгет-нәсыйхәт кыл, ә кимсетәсең килсә, син аны башка кешеләр бар чакта эшлә”, – дигән. Беркемнең башка кешеләр булганда кисәтү яки шелтә ишетәсе килмәс бит!**

Әгәр ниятләрең яхшы булып, син бу кешегә яхшылык теләсәң һәм ул чынлап төзәлсен дип уйласаң, аның белән ялгызың гына калып үгет-нәсыйхәтләреңне бирергә кирәк. Хәзер кайбер кешеләр төрле дини темаларга бәхәс куертырга ярата, алар бу вакытта үзләрен диннең сафлыгы һәм башка шундый изге максатлар өчен көрәшүчеләр итеп күрсәтергә тырыша. Хакыйкатьтә, мондый чакта кемне дә булса чынлап торып төзәтергә теләгән кеше алар белән аерым калып сөйләшкән булыр иде. (Ягъни, чит кешеләрдән башка гына андый бәхәсле мәсьәләләрне тикшерерләр иде.) Ә алар моның нәкъ киресен эшли: кешеләр күп булганда бер-берләре белән низагка керә, ызгыша башлый; моны бары тик үзләренә халык игътибарын җәлеп итәргә тырышу дип кенә аңларга була.

***Рәшид ИСАЕВ***

## Юмартлык (сәхавәт)

**Үз диненең үгет-нәсыйхәтләрен тотучы мөселман киң күңелле һәм юмарт була.**

**Ул һәрвакыт юмартлык белән эш итә. Чөнки ул үз малыннан Аллаһ юлына өлеш чыгарганда, аның ике дөньяда да зур файда китерәчәген белә. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Байлыкларын Аллаһ юлында сарыф итүчеләр – һәрберсе йөзәр бөртекле җиде башак бирә торган бөртек утыртучыга тиң. Ә Аллаһы Тәгалә теләгән кешесенә аннан да арттырып бирә. Аллаһы Тәгалә – һәрнәрсәне Колачлаучы, Белүчедер!»**

*Юмартлык* (***гарәпчә*** сәхавәт) **мөселманның иң яхшы сыйфатларыннан берсе булып санала. Нәкъ менә шуңа күрә бер сәхабәнең: «Исламда иң яхшы сыйфат кайсы?» – дигән соравына Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Кешеләрне сыйла һәм танышларыңа да, таныш түгелләргә дә сәлам бир», – дип җавап биргән.**

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлам сәхабәләрен гел юмартлыкка өйрәткән; алар муллыкта яшәп, Аллаһы Тәгаләне истән чыгармасын өчен, күңелләрендәге байлык җыю хисен бетерергә тырышкан.**

# ИГЕЛЕК КЫЛЫРГА АШЫК!

**Үксез, ятим, авыру балалар язмышына күбебез битараф түгел. Ә бит игътибар, кайгыртучанлык күрсәтеп, тормыш-көнкүреш шартларын яхшыртып, алар өлешенә тигән «көмеш»не җиңеләйтеп тә була. Нәкъ менә шундый ният белән Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең “Зәкят” хәйрия фонды инвалид балаларга ятимнәр приюты ачу өчен акча җыю эшенә кереште. Сез дә, хөрмәтле дин кардәшләребез, милләттәшләребез, шушы изге эшкә кушыла аласыз. Моның өчен** ЗАКЯТ **сүзе белән** 7715 номерына SMS-хәбәр **җибәрергә мөмкин (50 сум акча тотып калыначак). Биектау бистәсендәге приютка тәгаенләнгән бинаны төзекләндерү өчен алты миллион сум акча кирәк.**

## Акча күчерү өчен банк реквизитларын да тәкъдим итәбез.

**НАИМЕНОВАНИЕ СБОРА “САДАКА”.**

**Благотворительный Фонд “Закят”.**

**ИНН/КПП 1655068682/165501001**
**ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012**
**р/с № 40703810362190000764**
**(Советское отделение № 6669/015 СБ РФ г. Казани)**
**ОСБ БАНК ТАТАРСТАН № 8610 г. Казани**
**к/с: 30101810600000000603 БИК: 049205603**
**Юридический адрес:**
**420111, г. Казань, ул. Лобачевского, д.6.**
**Телефон: +7 (843) 225-33-22.**

**Аллаһы Тәгалә үксезләргә күрсәткән ярдәмегезне кабул кылсын.**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №11-12 (206-207) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35420-35421.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 14 октябрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).